Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Кузайкино авыл Советы

КАРАРЫ

14 май 2019 ел № 95

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Кузайкино авыл Советы
карарларының үз көчен югалтуын
тану турында

Муниципаль норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү белән бәйле рәвештә, хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча

Кузайкино авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кузайкино авыл Советы карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

- 2016 елның 18 февралендәге “Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кузайкино авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва итүче гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кузайкино авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат Нигезләмәсе турында” № 21;

- 2016 елның 18 февралендәге “Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кузайкино авыл җирлеге муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва итүче гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» № 22;

- 2016 елның 30 мартындагы "Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кузайкино авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва итүче гражданнар һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кузайкино авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кузайкино авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның чикләүләрне үтәве буенча комиссия турында” № 24;

- 2016 елның 18 апрелендәге “Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кузайкино авыл Советының 2016 елның 18 февралендәге “Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кузайкино авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва итүче гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында” № 20 карарына үзгәрешләр кертү турындагы № 25;

- 2017 елның 20 сентябрендәге “Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кузайкино авыл Советының 2016 елның 18 февралендәге “Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кузайкино авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва итүче гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кузайкино авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте

һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат Нигезләмәсе хакында" № 21 карарына үзгәрешләр кертү турында" №51;

2. Әлеге карарны Кузайкино авылы, Совет урамы, 26 нчы йорт торак пунктлар территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендта халыкка җиткерергә, "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет" челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Кузайкино авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Кузайкино
авыл җирлеге башлыгы А.Ф. Шәйхетдинов